КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 август г.Казань № 692

Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Карарга теркәлгән Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен расларга

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип таныргa:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары белән расланган «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2017 ел, 13 март, 138 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 апрель, 244 нче карары белән расланган «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 31 октябрь, 828 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 март, 165 нче карарының 2 пункты.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 17 август, 692 нче
карары белән расланды

Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан гамәлгә куючы (гамәлгә куючыларның берсе) Татарстан Республикасы булган коммерциячел булмаган оешмаларның Татарстан Республикасында табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру буенча чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба – субсидияләр, коммерциячел булмаган оешмалар).

2. Субсидияләр эшчәнлекнең төп максаты булып «Балаларга өстәмә белем бирү системасының яңа моделе» стратегик инициативасын тормышка ашыру торган коммерциячел булмаган оешмаларга табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү өчен бирелә:

табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә гомуми белем бирү программаларының һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә торган шартлар тудыру;

педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

балаларны федераль һәм төбәкара дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуга әзерләү, шул исәптән конкурсның төбәк этапларын уздыру;

укучыларның проект эшчәнлеге өчен реаль технологик бурычларны (шул исәптән сәнәгать предприятиеләре катнашында) хәл итүгә юнәлдерелгән өстәмә гомуми белем бирү программаларын эшләү;

бер мәсьәләне бергәләп хәл итү белән даими нигездә шөгыльләнүче өч кешедән ким булмаган мәктәп укучылары төркемнәренә ярдәм итү, шулай ук аларның инженерлык ярышларында катнашуларын тәэмин итү;

хакатоннар (төрле өлкәләрдәге программа белән тәэмин итү белгечләре (программистлар, дизайнерлар, менеджерлар) нинди дә булса проблеманы хәл итү өстендә бергә эшләгән чаралар) үткәрү;

балаларның проект эшчәнлеге буенча чаралар оештыру һәм үткәрү.

3. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга инвалид балаларга белем бирүне дә кертеп, өстәмә белем бирүне үстерү һәм

әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына (алга таба – баш бүлүчегә) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

үзгәртеп кору, бетерү процессында тормыйлар, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел;

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алучылар булып тормыйлар.

Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешмалар баш бүлүчегә түбәндәге документларны тапшыралар:

субсидия алу өчен баш бүлүче тарафыннан расланган форма буенча гариза (алга таба – гариза);

коммерциячел булмаган оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып);

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар сметасы;

килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче числосына түбәндәгеләрне раслый торагн документлар:

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләре булмау;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, коммерциячел булмаган оешманың үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, коммерциячел булмаган оешма

эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмауны раслый торган гарантия хаты;

Документлар коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә тапшырыла.

Кәгазьдә бирелгән барлык документлар да төгәл бастырып чыгарылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, коммерциячел булмаган оешманың вәкаләтле вәкиле имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазьдә бирелгән гаризаның барлык битләренә дә сан сугылган булырга тиеш. Кәгазьдә бирелгән гариза тегелгән һәм коммерциячел булмаган оешманың вәкаләтле вәкиле имзасы белән таныкланган һәм гаризаның икенче ягында битләрнең гомуми санын күрсәтеп, мөһер (мөһер булган очракта) белән беркетелгән булырга тиеш.

Коммерциячел булмаган оешма тарафыннан әлеге пунктның алтынчы абзацында каралган документ тапшырылмаган очракта, баш бүлүче күрсәтелгән документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

6. Баш бүлүче сайлап алуны үткәрү турында карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында сайлап алу турында игълан урнаштыра.

Гаризалар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә конкурс үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң календарь көннәрдә исәпләнгән 10 көн эчендә кабул ителә.

7. Гариза баш бүлүче тарафыннан кергән көнендә теркәлә.

Сайлап алуда катнашу өчен бер генә гариза да бирелмәгән очракта, сайлап алу мөмкин түгел дип таныла.

8. Гариза теркәлгәннән соң ике эш көне эчендә баш бүлүче тарафыннан әлеге Тәртип таләпләренә туры килү-килмәүгә тикшерелә. Баш бүлүче гаризаларны кабул итү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны комиссиягә җибәрә.

9. Комиссия тапшырылган документларны 14 көн эчендә карый. Сайлап алу комиссия тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән башкарыла. Комиссия составы баш бүлүче тарафыннан раслана. Сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән гаризалар тапшырган яисә гаризалар тапшырган коммерциячел булмаган оешмалар штатында торучы), йә сайлап алуда катнашучылар йогынты ясарга сәләтле затлар комиссия әгъзалары була алмый.

10. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы була. Карар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлары тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч тавыш булачак.

11. Гаризаларны караганда комиссия түбәндәге критерийларга таяна:

коммерциячел булмаган оешманың устав максатлары, бурычлары һәм эшчәнлек төрләре табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирүне үстерү мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән;

Татарстан Республикасында балаларга табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе бар;

коммерциячел булмаган оешма, федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә субсидия алу хокукына сайлап алу игълан ителгәнчегә кадәр өч елдан да ким булмаган вакыт эчендә теркәлгән;

коммерциячел булмаган оешмада өч еллык эшчәнлек планы бар, ул Татарстан Республикасында табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирүне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне күздә тота.

Гаризалар биш баллы шкала буенча (1дән 5кә кадәр) һәр критерий буенча баш бүлүче тарафыннан расланган форма буенча тавыш бирү кәгазенә баллар кертү юлы белән бәяләнә.

Субсидияләр гаризасы иң күп балл җыйган коммерциячел булмаган оешмага бирелә. Баллар тигез күләмдә булса, субсидия гаризасы иртәрәк тапшырылган коммерциячел булмаган оешмага бирелә.

12. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча комиссия сайлап алу җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итә.

13. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны комиссия сәркатибе алып бара. Беркетмә комиссия утырышы узган көнне комиссия рәисе тарафыннан раслана.

14. Беркетмә расланганнан соң бер эш көне эчендә баш бүлүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Комиссиянең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына коммерциячел булмаган оешма тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

16. Баш белгеч:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә беркетмә урнаштырылганнан соң бер көн эчендә субсидия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча килешү төзи.

17. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртипнең 4 һәм 11 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бирелгән гаризада һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларда мәгълүматның дөрес булмавы;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга баш бүлүчегә билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

Бюджет йөкләмәләре лимиты булган очракта коммерциячел булмаган оешмалар киләсе финанс елында билгеләнгән таләпләргә туры килүгә тикшерүне кабат узмыйча гына субсидия алу хокукына ия.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, баш бүлүче карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә бу хакта коммерциячел булмаган оешмага хәбәр җибәрә.

18. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидияләрдән файдалану турында һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы;

баш бүлүченең коммерциячел булмаган оешма тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм рәвешләрен билгеләү хокукы;

субсидияне (субсидия калдыкларын) кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, баш бүлүче тарафыннан аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә;

коммерциячел булмаган оешманың һәм субсидияләр бирү турындагы килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның, баш бүлүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан коммерциячел булмаган оешма тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, коммерциячел булмаган оешма тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләрне үтәүне тикшерү өчен ризалыгы;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, чит ил валютасы акчалары исәбенә сатып алуны тыю.

19. Субсидияләр (С) күләме шундый ук товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_{з} + З_{р.м} + З_{а} + З_{с} + З_{к} + З_{п.о} + З_{и.к} + З_{к} + З_{о.к.о},$$

монда:

$З_{з}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен хезмәт өчен түләү фондыннан салымнарны да кертеп, хезмәт өчен түләү фондына чыгымнар;

$З_{р.м}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен чыгым материаллары сатып алуга чыгымнар;

$З_{а}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру өчен биналарны арендага алу хезмәте күрсәтүгә чыгымнар;

$З_{с}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен элемтә хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

$З_к$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен хезмәт күрсәтүче оешмалар (клининг) хезмәтләренә чыгымнар;

$З_{п.о}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен оргтехника һәм программа белән тәэмин итү (банк хезмәтләре чыгымнарын да кертеп) сатып алуга чыгымнар;

$З_{и.к}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмати-консультация хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

$З_к$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен командировкага чыгымнар, вәкиллекле чыгымнар;

$З_{о.к.о}$ – төп (мәҗбүри) комплект җиһазлар сатып алуга, шул исәптән табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өчен алып килү һәм җибәрү-көйләү эшләренә чыгымнар.

20. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып түбәндәге күрсәткечләргә ирешү тора:

Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган техник юнәлештәге өстәмә гомуми белем бирү программалары белән тәэмин ителгән 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар саны – кимендә 460;

балалар технопаркларының ачык чараларында катнашкан балалар саны – кимендә 1312;

балалар технопаркларында эшләүче өстәмә һөнәри программалар буенча ел саен белем алган педагогларның өлеше –кимендә 33 процент;

проект эшчәнлеге нәтиҗәләрен тәкъдир итү буенча региональ һәм федераль Хисап чараларында тәкъдим ителгән балалар технопаркларында белем алучы балалар тарафыннан тормышка ашырылган проектлар саны – кимендә 19;

балаларның проект эшчәнлеге өчен реаль технологик бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән өстәмә белем бирү программалары саны – кимендә 7;

технопарклар базасында инженер проектларын даими нигездә гамәлгә ашыручы өч кешедән ким булмаган мәктәп укучылары төркемнәре саны –кимендә 13;

анда балалар технопаркларында белем алучы балалар катнашачак үткәрелгән инженерлык хакатоннары, инженерлык ярышларының төбәк этаплары, техник һәм табигый-фәнни юнәлештәге төп ярышлар һәм конкурс чаралары саны – кимендә 5;

балалар технопарклары оештырган балаларның проект эшчәнлеге буенча ачык чаралар саны – кимендә 4.

21. Баш бүлүче субсидияне, килешүдә билгеләнгән субсидияне күчерү графигы нигезендә, коммерциячел булмаган оешманың Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә:

агымдагы финанс елының I кварталы өчен – килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә;

агымдагы финанс елының II – IV кварталлары өчен – әлеге Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән, алдагы квартал өчен хисап бирелгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә.

22. Коммерциячел булмаган оешма субсидия алу һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтер исәбен алып бара.

23. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы булган очракта, коммерциячел булмаган оешманың аны куллануга ихтыяҗы турында карар баш бүлүче тарафыннан кабул ителә.

Әлеге карар булмаган очракта, коммерциячел булмаган оешма хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр субсидия калдыгын Татарстан Республикасы бюджеты керменә кайтарырга тиеш.

24. Баш бүлүче тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге Тәртипнең 23 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, коммерциячел булмаган оешма финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы.

25. Коммерциячел булмаган оешма квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр, шулай ук хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр, баш бүлүчегә субсидияне әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча субсидияне куллану турында хисап һәм әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча  субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирә.

26. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм баш бүлүче законнар нигезендә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тота.

2. Баш бүлүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланса, коммерциячел булмаган оешма баш бүлүченең тиешле таләбен алган көннәе алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендәтиешле акчаларны  Татарстан Республикасы бюджеты керменә кире кайтарырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

субсидияләрдән файдалану һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта  – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән мәгънәсе өчен – тулы күләмдә;

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә;

28. Татарстан Республикасы бюджеты керменә әлеге Тәртипнең 23 һәм 27 пунктларында күрсәтелгән очракларда ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, баш бүлүче, субсидия кире кайтару срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән  җиде көн эчендә, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керменә кайтару буенча чаралар күрә.

29. Субсидиянең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшерүдә тоту Россия Федерациясе законнары нигезендә баш бүлүче тарафыннан башкарыла.

---